**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«11» 04 2025 ел Яр Чаллы № 1184

Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген раслау турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^{4}$статьясы 3 пункты нигезендә, «Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы 4 өлеше $2^{3}$ пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль берәмлеге территориясендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген расларга.
2. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чараларын гамәлгә ашыручы Тукай муниципаль районы башкарма комитетына ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсеше өлкәсендә «ДОБРО.РФ» бердәм мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла торган ярдәм чаралары турында мәгълүматны вакытында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы И.Р. Гәрәевкә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның «11» апрелендәге 1184 номерлы карарына кушымта

Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеге

| № | Ярдәм чарасы | Ярдәм чаралары өчен җаваплы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | Финанс ярдәме | |
| 1. | Районның 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү» программасы кысаларында яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга физик затларга грантлар бирү | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | Оештыру ярдәме | |
| 2. | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге тарафыннан чаралар (форумнар, слетлар, семинарлар) үткәрү | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 3. | Ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) шәхси кенәгәләрен рәсмиләштерүдә ярдәм | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 4. | Ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) оешмалары чараларын оештыру һәм үткәрү өчен биналар (мәйданчыклар) бирү | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлеге |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 5. | Ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) район Яр Чаллы шәһәре һәм Татарстан Республикасының танылган шәхесләре белән тематик очрашуларын оештыру | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 6. | Ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәте вәкилләренең, шул исәптән «көмеш» волонтерларның (55 яшьтән олкәнрәк гражданнар) форумнарда, слетларда, семинарларда, конференцияләрдә, мастер-классларда катнашуында ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы |
| | Ирекле ярдәмчеләрне (волонтерларны) муниципаль район Башлыгы катнашындагы чараларда катнашырга чакыру | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Мәгълүмати ярдәм | | |
| 7. | Агымдагы ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) проектларын, чаралар, программалар, акцияләр, иң яхшы практикалар, социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы активистлар, федераль, региональ һәм муниципаль конкурсларда җиңүче коммерциясез оешмалар һәм/яисә ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләре вәкилләре турында рәсми мәгълүмат ресурсларында мәгълүмат урнаштыру | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль волонтерлык үзәге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Тукай муниципаль районы матбугат хезмәте, "Якты юл" газетасы |